**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3285**
**28.06.2019**

Аукционда муниципаль мөлкәтне сату турында нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 3.18, 5.24 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитет Җитәкчесенең 2006 елның 13 ноябрендәге 4341 нче карары белән (Башкарма комитетның 2009 елның 16 сентябрендәге 4003 нче, 2010 елның 13 сентябрендәге 5810 нчы, 2014 елның 21 июлендәге 4257 нче, 2015 елның 4 сентябрендәге 4948 нче, 2018 елның 6 апрелендәге 1890 нчы карарлары редакциясендә) расланган аукционда муниципаль мөлкәтне сату турында нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац белән тулыландырырга:

«Катнашучылар составы буенча аукцион ачык булып тора. Муниципаль мөлкәт бәясе турында тәкъдимнәр аукционда катнашучылар тарафыннан ачык рәвештә сатуларны үткәрү барышында белдерелә.»;

2) 1.3 пунктның уникенче абзацында «ачык» сүзен төшереп калдырырга;

3) 2.2.1 пунктта «шулай ук мөлкәт бәясе турындагы тәкъдимнәрне кертү ачык рәвештә булганда» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 2.2.6 пунктта «, шулай ук мөлкәт бәясе турындагы тәкъдимнәрне кертү ябык рәвештә булганда, мөлкәт бәясе турында тәкъдимнәр» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 2.2.10 пунктта «мөлкәт бәясе турындагы тәкъдимнәрне ачык рәвештә кертеп, аукцион үткәрелгән очракта» сүзләрен төшереп калдырырга;

6) 2.2.11 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 2.3 пунктта «2.2.11» цифрларын төшереп калдырырга;

8) 4.2 пунктта:

- беренче абзацта «(яки мөлкәт бәясе турындагы тәкъдимнәрне кертү ачык рәвештә булганда – аукционда катнашучыларны билгеләү көнендә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

- икенче абзацта «(мөлкәт бәясе турындагы тәкъдимнәрне кертү ачык рәвештә булганда)» сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 4.5 пунктта «мөлкәт бәясе турындагы тәкъдимнәрне ачык рәвештә кертеп» сүзләрен төшереп калдырырга;

10) 4.6 – 4.6.5 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

11) 4.10.1 пунктта «ачык» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин